**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 17 июле №281

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең милеккә (шул исәптән җир кишәрлекләренә) ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында муниципаль милек реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендагы 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Бишнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең милеккә (шул исәптән җир кишәрлекләренә) ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында муниципаль милек реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча өлешен тапшырырга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.
3. Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыруны гамәлгә ашыру Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Яшел Үзән муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә ашырыла.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр составында Яшел Үзән муниципаль районының информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк

урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Бишнә авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

**Бишнә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**